| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИКБУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИКБАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

КАРАР

27 март 2020 ел. №4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Бикбау авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының "Җирле референдум турында"гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Бикбау авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Мардамшина Л.Н.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
Дата 27 март  2020 ел. N 4

ТР Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү (1 нче төркем инвалидлардан, БВС ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, кайнар нокталарда хезмәт итүчеләр һәм  аларның  тол хатыннарыннан,  күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:

а) авыру;

б) озакка сузылган командировка;

өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү керту кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N _______________ Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ___________________________________________________________

Адресы: ______________________________________________________________________

_______________________________________________________________ нигезендә

Сезгә _____________ срокка кадәр ________________________ чараларны гамәлгә

__________________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада ________________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:____________________

Түләү алучы банкның БИК _________________________________________________________
Сч. N ________________________________________________________________________
Кабул итүче Сч. N ____________________________________________________________
КПП __________________________________________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләү билгеләнеше ______________________________________________________________
Җитәкче __________________ _________________________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N ___________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында _______________________
__________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада _________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. _________________________________________________________
Адресы: _____________________________________________________________________
Алдым "___" ________________ 20___ ел. _______________________________________

______________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең

шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.